СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.06.2025 г. Агрыз № 47-9

«Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан адреслау объектларына адреслар бирү, урам-юл челтәре элементларына исемнәр бирү һәм җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, адреслар һәм исемнәрне үзгәртү, мәгълүматны дәүләт адреслар реестрында урнаштыруны гамәлгә турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2023 елның 25 апрелендәге 28-8 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан адреслау объектларына адреслар бирү, урам-юл челтәре элементларына исемнәр бирү һәм җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, адреслар һәм исемнәрне үзгәртү, мәгълүматны дәүләт адреслар реестрында урнаштыруны гамәлгә турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2023 елның 25 апрелендәге 28-8 номерлы карар үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына адреслар бирү, урам-юл челтәре элементларына исем бирү, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исем бирү, адреслар һәм исемнәр бирү, мәгълүматны дәүләт адреслар реестрында урнаштыру буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы карарның үз көчләрен югалткан дип танырга тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә

ашыруны кабул итү-тапшыру турында төзелгән килешүләрне өзү процедурасын әлеге карарның 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән карарлар нигезендә үткәрүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе урынбасары,
Муниципаль район Башлыгы урынбасары И.И.Ямалиев